ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» июль 2026 ел № 642

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында**

Татарстан Республикасы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга (алга таба текст буенча – махсус хәрби операциядә катнашучыларга) һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм мәсьәләләре буенча төбәк ведомствоара комиссия тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру максатларында (2026 елның 5 июнендәге ЛФ-12-201 номерлы беркетмәсе), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм мәсьәләләрен хәл иткәндә оператив карарлар кабул итүне һәм ведомствоара нәтиҗәле хезмәттәшлекне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзергә һәм аның составын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Башкарма комитетның структур бүлекчәләре җитәкчеләренә, шулай ук Арча муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына комиссиягә үз компетенцияләре чикләрендә тиешле ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Г.Шәймәрдановага йөкләргә.

Җитәкче Л.И.Абдуллин

Арча районы
башкарма комитетының
№642, 23 июль 2024 ел
карарына
1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия составы**

| | |
|---|---|
| **Мөхәмәдияров Рамил Данил улы** | **Арча муниципаль район башлыгы урынбасары, комиссия рәисе (килешү буенча);** |
| **Абдуллин Ленар Ильсурович** | **Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары;** |
| **Шаймарданова Разиля Габделнуровна** | **Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия сәркатибе;** |
| **Комиссия әгъзалары:** | |
| **Латыйпова Алинә Илдар кызы** | **“Ватанны саклаучылар” махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча Арча районындагы филиалының социаль координаторы (килешү буенча);** |
| **Хәсәнов Илнур Мәхмүт улы** | **Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе;** |
| **Ганиева Эльмира Нияз кызы** | **“Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы” МКУ җитәкчесе (килешү буенча);** |
| **Сиражиев Илһам Гапделнур улы** | **Арча муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе (килешү буенча);** |
| **Идрисов Рифат Илшат улы** | **“рча үзәк район хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесы баш табибы (килешү буенча);** |
| **Мифтахетдинова Надия** | **Татарстан Республикасында кеше хокуклары** |

| | |
|---|---|
| **Равил кызы** | **буенча вәкаләтле вәкилнең Арча районында җәмәгать ярдәмчесе (килешү буенча);** |
| **Гыйбадуллина Гөлфия Мансур кызы** | **ТР халыкны эш белән тәэмин итү үзәге дәүләт казна учреждениесенең Арча районындагы бүлек җитәкчесе (килешү буенча);** |
| **Гобәйдуллин Айрат Дамир улы** | **Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге җитәкчесе (килешү буенча);** |
| **Нурмөхәммәтова Рузия Илсур кызы** | **Арча муниципаль районында Россия Социаль фондының клиентлар хезмәте бүлеге җитәкчесе (килешү буенча);** |
| **Сәгыйтова Ләйсән Гарәфетдин кызы** | **Арча район Советы аппаратының юридик мәсьәләләр бүлеге җитәкчесе (килешү буенча);** |
| **Муллахмәтов Нияз Наил улы** | **Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" муниципаль учреждениесе җитәкчесе;** |
| **Әюпов Илфар Илдар улы** | **Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәдәният идарәсе" муниципаль учреждениесе җитәкчесе;** |
| **Һидиятуллин Фәнил Фәнис улы** | **Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге җитәкчесе;** |
| **Ибраһимова Динә Мансур кызы** | **Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге җитәкчесе (килешү буенча);** |
| **Сахаров Эдуард Виктор улы** | **Татарстан Республикасы Арча һәм Әтнә районнары хәрби комиссары (килешү буенча);** |
| | **Арча муниципаль районының авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча).** |

Арча районы
башкарма комитетының
№642, 23 июнь 2022 ел
карарына
2нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Арча муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье һәм Херсон өлкәләре территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучы (алга таба – махсус хәрби операциядә катнашучылар) Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм күрсәтү, Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары структур бүлекчәләренең, Арча муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы башка оешмаларның һәм учреждениеләрнең, хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә ярдәм күрсәтүгә җәлеп ителүче волонтерлык төркемнәренең ведомствоара хезмәттәшлеген координацияләү һәм тәэмин итү һ.б. максатдарда төзелде.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына һәм норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Комиссиянең төп максатлары булып тора:

2.1 Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең, район территориясендә урнашкан башка оешмаларның махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрләрне оператив хәл итү максатында социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.

2.2. Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә, район территориясендә урнашкан башка оешмаларга махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаиләләренең тиешле социаль ярдәм чараларын алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр эшләү.

2.3. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның яисә комиссиягә кергән гаилә

әгъзаларының гаризаларын карау. Комиссиягә кергән хәбәрләр һәм мөрәҗәгатьләр буенча җавап әзерләү (идарә карары кабул итү) 5 эш көненә кадәр гамәлгә ашырыла.

2.4. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

2.5. Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан комиссия тәкъдимнәрен үтәү мониторингы.

**3. Комиссиянең хокуклары**

3.1. Комиссия эше өчен кирәкле мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә соратып алу.

3.2. Комиссия эшендә катнашу өчен Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын һәм белгечләрен, шулай ук район территориясендә урнашкан оешма вәкилләрен җәлеп итү (килешү буенча).

3.3. Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә, район территориясендә урнашкан башка оешмаларга махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаиләләренең иҗтимагый социаль ярдәм алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итү.

**4. Комиссия эшчәнлеге**

4.1. Комиссия составы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары белән раслана. Комиссия рәис, аның урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

4.2. Комиссия рәисе булып Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары тора, ул комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә һәм аның утырышларын алып бара. Комиссия рәисенең урынбасары була, ул булмаганда комиссия рәисе вазыйфаларын башкара.

4.3. Комиссия үз эшчәнлеген махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре мөрәҗәгатьләре кергән саен уздырыла торган утырышлар рәвешендә гамәлгә ашыра. Комиссия утырышының көн тәртибе комиссия әгъзаларының тәкъдимнәрен исәпкә алып төзелә һәм рәис тарафыннан раслана.

4.4. Комиссия әгъзалары утырышта шәхсән катнашалар.

4.5. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул рәис һәм сәокатип тарафыннан имзалана.

4.6. Комиссия беркетмәсен комиссия сәркатибе алып бара. Беркетмә

комиссиянең барлык әгъзаларына һәм комиссия утырышында катнашучы башка затларга җибәрелә.

4.7. Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итүне комиссия сәркатибе гамәлгә ашыра.

Шул максаттан комиссия ссзркатибе:

- материалларны комиссия утырышларына әзерләүне оештыра;

- комиссия әгъзаларына утырышны үткәрү урыны, вакыты турында мәгълүмат бирә, кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

- комиссия утырышларының беркетмәсен төзи һәм кабул ителгән карарларны практикада куллану барышы турында комиссиягә хәбәр итә.